| ГЛАВА БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 февраль, 2024 Олы Подберезье ав. № 5

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Сосновка торак пунктында рожданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 нче карарына үзгәреш кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Сосновка авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Советының Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыены әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 30 сентябрендәге 20 номерлы карары нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. 2024 елның 18 мартында 16 сәг 00 минутта Сосновка авылы, Яр буе урамы, 31 нче йорт адресы буенча авыл мәдәният йорты бинасында «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Олы Подберезье торак пунктында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 1 нче карарына үзгәреш кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«Сез «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Сосновка торак пунктындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 нче карарына җирле әһәмияттәге сорауларны хәл итү буенча эшләр исемлеге өлешендә үзгәртергә һәм 2024 елда

алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерергә ризамы:

торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка таратырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавалылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Подберезье авыл җирлеге Башлыгы О.М.Емельянова